# Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл жирлеге Советы карары

**2018 елның 30 ноябре** **№122**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Алан авыл җирлеге территориясендә физик затлар милкенә салым турында"гы 2014 елның 21 ноябрендәге 122 нче санлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, "Россия Федерациясе Салым кодексы 52нче статьясенең беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында"гы 2018 елның 03 августындагы 334-ФЗ санлы Федераль законга туры китереп, Алан авыл җирлеге Советы карар кабул итте,

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге территориясендә физик затлар милкенә салым турында"гы 2014 елның 21 ноябрендәге 122 нче санлы карарына (2015 елның 8 нче маендагы 151 нче санлы, 2015 елның 13 нче октябрендәге 5 нче санлы, 2018 елның 12 апрелендәге 94 нче санлы редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.түбәндәге эчтәлектәге 3.2 пункты өстәргә:

"3.2. Түбәндәге физик затларны милек салымыннан азат итәргә:

3.2.1. 18 яшькә кадәрле дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булганнарны;

3.2.2 әлеге пунктның 3.2.1 пунктчасының күрсәтелгән гражданнарның балаларын;

3.2.3. тулы дәүләт тәэминатында булмаган инвалид балаларның ата-аналарын (уллыкка/кызлыкка алучылар, опекуннар, тәрбиягә алучылар).

Салымга ташламалар түбәндәге объектларга каралган:

1) фатир, фатирның бер өлеше яки бүлмә;

2) торак йорт яки торак йортның бер өлеше.

Салымга ташлама, салым түләүченең теләге буенча, гаилә карамагындагы бер генә объектка бирелә.

Салымга ташлама Алан авыл жирлеге территориясендә даими яшәүче салым түләүченең милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге максатларында кулланылмаучы объект өчен тиешле салым күләмендә бирелә.

Салымга ташламага хокукы булган физик затлар салым органына салымга ташлама бирү турында гариза яза, шулай ук салым түләүченең салымга ташламага хокукын раслаучы документлар тапшыра ала.

Салымга ташламага хокукны раслаучы документлар булып әлеге төр салым түләүче физик затның шәхесен раслаучы документ, шулай ук аның исемена бирелгән күп балалы гаилә таныклыгы, яки өч һәм аннан да күбрәк балаларның туу турындагы таныклыклары тора.

Салымга ташламалы объектны сайлавы турында салым түләүче салым органына салым чоры булган елның 1 ноябренә кадәр хәбәр итәргә тиеш. Шушы вакыттан күрсәтелгән объектларга салымга ташлама кулланыла башлый.

2.Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәренең Алан авыл җирлеге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3.Карарның 1 пунктында күрсәтелгән 3.2 пункты рәсми бастырып чыгарганнан соң бер ай үткәч көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан гамәлдәге хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

Алан авыл җирлеге башлыгы Ә.Г.Хаҗиев